БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
27 апрель 2023 ел

**КАРАР**
№ 189

**Балтач район Советының кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2019 елның 15 мартындагы 168 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарны;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2019 елның 17 декабрендәге 227 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы карарны;

1.3. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2011 елның 28 октябрендәге 65 номерлы «Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау һәм аларны күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү турында»гы карарны;

1.4. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2011 елның 28 октябрендәге 59 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җир кишәрлекләренә карата гавами сервитутлар билгеләү һәм аларның гамәлдә булуын туктату тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарны.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов